Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559 ) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2022 ел №94

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында”2012 елның 3 декабре 230-ФЗ номерлы Федераль законына туры китерү максатларында, Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2017 елның 20 сентябрь 69нчы номерлы карары белән расланган «Җәлил шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифалар һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырылган мәгълүматны “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштыру, бастыру өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәреш кертергә:

- 3нче пунктның “г” пунктчасында“, акцияләр” сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 21.07.2021 № 44 2021 елның 21 июль 44нче номерлы карары белән расланган “Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазифаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны “Сарман муниципаль районы” муниципаль

бераемлеге җирле үзидарә органнары рәсми сайтларына урнаштыру һәм бастыру өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә” үзгәреш кертергә:

- 2нче пунктның «г» пунктчасында «, акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтындаhttps://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Р.Ә.Кәримов